СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.03.2025 г. Заинск № 387

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2016 елның 26 августындагы 135 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 30 ноябрендәге 444-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2016 елның 26 августындгы 135 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында Нигезләмәнең 6 статьясына түбәндәге эчтәлекле 1.1 өлеш өстәргә:

«1.1. Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән объектка карата килешү төзү, әгәр килешү төзелгән вакытка мондый объект Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объекты (тарихи һәм мәдәни ядкарь) яисә ачыкланган мәдәни мирас объекты булса, рөхсәт ителми.».

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары П. С. Уразайкинга йөкләргә.

**Совет рәисе** **Р.Г. Кәримов**